**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2024лның 22 ноябре** **91 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге составына керүче Кече Кабан торак пунктында (Луговая ур., Зеленая ур., Славный тыкр., Муса Җәлил ур., ТАССРның 100 еллыгы ур., Гвбдулла Тукай ур., территориясе өлешендә) 2025 елга үзара салым кертү буенча гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегендәге Кече Кабан торак пункты(Луговая ур., Зеленая ур., Славный тыкр., Муса Җәлил ур., ТАССРның 100 еллыгы ур., Гвбдулла Тукай ур.,, территориясе өлешендә ) гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең Кече Кабан торак пункты территориясендә (Луговая ур., Зеленая ур., Славный тыкр., Муса Җәлил ур., ТАССРның 100 еллыгы ур., Гвбдулла Тукай ур.,., территориясе өлешендә**)** яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 5000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Луговая ур., Кече Кабан авылы);
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече Кабан авылы, балалар мәйданчыгы)эшләре өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-

http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ И.Г. Шәрәфиев

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Олы Кабан
авыл җирлеге Советы рәисе: _________________ И.Г. Шәрәфиев